Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлегенең Смәел торак пунктында ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
№2

27 ноябрь, 2023 ел.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлегенең Смәел торак пункты халык җыены карар бирә:

1. Смәел авыл җирлегенең Смәел торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

95% күләмендә балачактан инвалидларга, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләргә, ялгыз өлкән яшьтәге пенсионерларга, Россия армиясендәге гражданнарга, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына 50% күләмендә көндезге бүлектә укучы студентларга ташламалар ясарга.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару өчен юлларга:

-Смәел торак пункты зиратының коймаларын төзекләндереп буяу;

- Смәел торак пунктының Яшьләр урамындагы, Киров урамындагы юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү;

- Смәел торак пунктының Бауман урамы, М. Җәлил урамы, Г. Тукай урамы, Киров урамындагы асфальт юл ярыкларын битум белән ябу;

- Смәел торак пунктының Киров урамында агачларны кисү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, http:// pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р. Г. Йосыпов